ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.11.2022 с.Старое Дрожжаное № 620

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 25 октябрендәге 556 номерлы «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 25 октябрендәге 556 номерлы «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашучы, һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында»;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылучылар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылучы гражданнарны, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче Россия Федерациясе милли гвардиясендә, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, Татарстан Республикасы

буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) карата түбәндәге өстәмә чараларны билгеләргә:»;

2 нче пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм рәсми сайтында бастырырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе: Д.А. Сатдинов